Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советының 2022 елның 5 сентябрендәге номерлы «Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы терлекләрен тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2021 елның 6 декабрендәге N397-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге Советы карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Болын-Балыкчы авыл җирлегенең 2013 елның 06 июнь дагы 64 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районының Болын-Балыкчы авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы терлекләрен тоту кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 2.10 һәм 2.11 пунктлар өстәргә:

«2.10.1993 елның 14 маендагы N 4979-I “Ветеринария турында” Россия Федерациясе Законының 19.1 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, терлекләрне маркировкалауны тәэмин итәргә.

2.11.«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 19.1 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, хайваннарны исәпкә алу өчен кирәкле белешмәләрне, хайваннарны исәпкә алуны гамәлгә ашыручы затларгахайваннарны маркирлау һәм исәпкә алу ветеринария кагыйдәләрендә билгеләнгән исемлек һәм сроклар буенча тапшырырга.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.ветеринария өлкәсендәге белгечләргә аларның таләбе буенча хайваннарга карау һәм исәпкә алу өчен керү мөмкинлеге (йорт янындагы җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан торак урыннарга керүдән тыш), кичекмәстән әлеге белгечләргә көтмәгәндә үлү яисә хайваннарның бер үк вакытта массакүләм авыруы яки аларның гадәти булмаган тәртибе турында хәбәр итәргә;».

2.Әлеге карар 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

Җирлек башлыгыурынбасары Р.Х.Гильмутдинова